*Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын*

16+

# ТАТАРЛАР

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты газетасы

№ 18 (228). Сентябрь 2024 ел



*Танылган яшь җырчы Сәйдә Мөхәмматҗанова.*

*Сәйдә Мөхәмматҗанова белән әңгәмә – газетабызның 4 нче битендә.*

*Денис Богомолов фотосы.*

## КЫСКА ХӘБӘРЛӘР

**Саха (Якутия) Республикасына** эш сәфәре кысаларында Татарстан Республикасының Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев Республика башлыгы Айсен Николаев белән очрашты.

**Анталия** тарихын өйрәнү үзәге китапханәсендә татар бүлеге ачылды. Чарада Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров һәм Анталия мэрының урынбасары Дурмуш Али Арслан катнашты.

**Ростов өлкәсендә** сакланып калган бердәнбер татар авылы – Кызыл авылына (Кзыл Аул) 90 ел тулуга багышланган тантаналы бәйрәм чарасы уздырылды.

**Санкт-Петербург шәһәре** татар милли-мәдәни автономиясе Татар мәдәни үзәгендә татар теле курслары яңадан башланып китте. К(П)ФУның Каюм Насыйри институты мәдәни-белем бирү үзәгендә Санкт-Петербургның «Ак калфак – Нева» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы вәкиле, методист-укытучы Фирая Рәшитова җитәкчелегендә беренче дәрес үткәрелде.

**Австралиядә** ел саен «MOSAIC» мәдәни фестивале оештырыла. Биредә гомер итүче татарлар быел икенче тапкыр катнаша. Чарага 30 дан артык милләт вәкиле җыелган.

**Мәскәүнең** «Дуслар» татар җыры ансамбле юбилеен билгеләп үтте. 5 ел элек оештырылган иҗат коллективы Мәскәү Татар мәдәни үзәген төрле чараларда уңышлы тәкъдим итә. «Дуслар» ансамбленең нигез салучысы һәм сәнгать җитәкчесе – Рәисә Кәбирова.

**Мордовиянең** Ләмбрә авылы «Алмаз» мәдәният сараенда «Авылым тавышлары» татар җыры фестиваль-конкурсы узды. Гаилә елына багышланган әлеге чара төбәкара дәрәҗәдә үткәрелде.

**Пенза өлкәсенең** Усть-Уза авылында «Ай, былбылым!» Төбәкара татар җыры һәм музыкасы фестивале узды.

**Башкортстанның** Туймазы районында татар калфагын тегү буенча осталык дәресе узды. Әлеге чара Башкортстанда милли кием көне уңаеннан үткәрелгән.

**Болгариядә** яшәүче башкорт һәм татарларны берләштерүче «Волжки булгари» иҗтимагый оешмасы һәм «Тарихи парк» бергә IV Халыкара традицион ризык фестивале оештырган.

pochta.ru



## Татарстан Республикасының Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыевның Бөтендөнья укытучылар көне уңаеннан котлавы

Хөрмәтле укытучылар, мәгариф хезмәткәрләре!

Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шурасы исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән Сезне һөнәри бәйрәмегез – Бөтендөнья Укытучылар көне белән тәбрик итәм.

Без нинди генә һөнәр иясе булсак та, нинди генә дәрәҗәләргә ирешсәк тә, барыбызның да хәреф танырга, укырга, язарга өйрәткән беренче укытучысы бар. Нәкъ менә укытучының һөнәри осталыгы, үз эшенә бирелгәнлеге киләчәктә бала тормышында әйтеп бетергесез мөһим роль уйный.

Россиядә укытучы һөнәренә, аларның авыр һәм җаваплы хезмәтенә карата игътибар елдан-ел арта бара. Ел саен илкүләм «Россия укытучысы» һәм башка абруйлы бәйгеләр уздыру шуның ачык бер мисалы булып тора.

Кадерле укытучыларыбыз, мәгариф хезмәткәрләре! Гүзәл бәйрәмегез уңаеннан сезгә саулык-сәламәтлек, имин көннәр, күңел тынычлыгы телим. Гомерегез буе укучыларыгызның ихтирамын һәм рәхмәтен тоеп яшәргә насыйп булсын. Бәйрәм белән Сезне!



# Татар ир-егетләре сынатмый

***Өлкә татар автономиясе тырышлыгы белән илебезне дошманнан саклаучы якташларыбызның якыннары хөрмәтенә Коръән уку мәҗлесе үткәрелде. Анда махсус хәрби операция зонасында хезмәт итүче дистәдән артык солдат һәм офицерның әниләре, хатыннары һәм балалары катнашты.***

Илебезнең матур киләчәге, иминлеге өчен сакта торучы ир-егетләребезне истә тоту, аларның гаиләләренә мөмкин кадәр ярдәм күрсәтү – һәрберебезнең изге бурычы. Татар автономиясе, «Ак калфак» оешмасы активистлары әлеге саваплы эштән читтә калмыйлар, һәрдаим үз өлешләрен кертергә тырышалар.

Мәҗлескә МХО зонасында батырларча һәлак булган Россия офицеры, хәрби очучы Тимур Кипчатовның хатыны Альбина Рамил кызы белән газиз баласы – кызы Лилиана килгән иде. Хәзерге вакытта Альбина солдат хатыннарына һәрьяклап ярдәм күрсәтү белән шөгыльләнә. Ул – Ватан батырлары гаиләләре комитетының төбәк бүлекчә җитәкчесе, «Герой хатыны» дип исемләнгән фотопроектны оештыручы.

Очрашуга шулай ук «Сердце Вновь Оживет» проекты җитәкчесе, илебез азатлыгы хакына газиз гомерен биргән Илдарның әнисе Резедә Ханнанова да чакырулы иде. Күптән түгел генә ике врач улларын югалту хәсрәтен кичергән Әлфия ханым Резедә Фариз кызы җитәкләгән оешмада үзенә юаныч, җанына тынычлык тапкан.

«Резедәгә зур рәхмәт, иң авыр минутларда ярдәменнән ташламады, яшәргә көч бирде», – ди Әлфия ханым.

Сабрия Хасанованың улы Фаил белән Гүзәлия Бәдретдинованың ире Фәнис язын снаряд кыйпылчыгы тиеп яраланганнар. Хәрби госпитальдә дәваланганнан соң алар яңадан сугышка киткән.

Засвияжье районы «Ак калфак» оешмасы активисты Дамирәнең ире Шамил алгы сафта булуына карамастан, гаиләсенең хәлен һәрвакыт белешеп тора. «Ак калфак»лылар Шамил хезмәт иткән частька даими рәвештә күчтәнәчләр җибәреп торалар – милли ризыклар пешереп, токмач кисеп озаталар.

МХОда катнашкан курку белмәс якташыбыз – Батырлык ордены белән бүләкләнгән Айрат Хәйруллинның әнисе Дилүзә барлык чараларда да актив катнаша. Хайруллиннар гаиләсе бер йодрык булып берләшеп, әлеге сынауны узалар. Бүген Дилүзә яраткан оныгын тәрбияләү белән мәшгуль.

Татар автономиясе рәисе Рамис Сафин очрашуда катнашучыларны сәламләп, чәчәк бәйләмнәре һәм истәлекле бүләкләр тапшырды.

«Татар ир-егетләре бервакытта да сынатмаган, Ватан, Туган ил хакына утка да, суга да кергән. Курку белмәс батырларыбыз илебез киләчәге өчен бүген дә алдынгылар сафында. Лачын уллар тәрбияләп үстергән аналарга зур рәхмәт», – диде ул.

Россия һава-десант гаскәрләре имамы Али хәзрәт Шәмшетдинов Коръәни-Кәримнең «Йәсин» сүрәсен укыды һәм шәһидләрнең рухлары шат булуын теләп дога кылдырды. «Ир-егетләребезгә туган нигезләренә исән-сау әйләнеп кайтырга насыйп итсен, ә якыннарына сабырлык юлдаш булсын», – диде Али хәзрәт Шәмшетдинов.

*Рузия ХӘЛИМОВА.*
*Ульяновск өләсе.*



# Герой белән очрашу

***Үз авылыбызда мәктәптә капиталь ремонт бару сәбәпле, Сафаҗай балалары бүген күрше Петрякс мәктәбендә белем ала. Әйтергә кирәк, биредә безне бик җылы кабул иттеләр, балалар да үзара уртак тел тапты. Бар чараларда да бергәләшеп бик теләп катнашалар. Мәсәлән, узган атнада ике авыл укучылары һәм укытучылары өчен Украина җирлегендә барган махсус операция катнашучысы белән очрашу оештырылды. Димәк, һәркемнең бүгенге Россиянең тарихи вакыйгаларында катнашучы белән турыдан-туры диалог корырга мөмкинлеге бар иде.***

Очрашу Герое – Әфган сугышы һәм МХО катнашучысы. Ул хисләнеп фронтта вакытта гаиләдән, туганнардан хәбәрләр яисә бөтенләй таныш булмаган балалардан чын күңелдән неонацистларны тизрәк җиңү теләге белән язылган хатларны алганда, никадәр җылы хисләр чолгап алуы белән уртаклашты.

Геройның чыгышын өлкән класс укучылары аеруча зур кызыксыну белән тыңлады һәм үзләрен кызыксындырган сорауларны бирде. Хөрмәтле кунак һәркайсына бик теләп җавап кайтарды һәм егетләргә армиядә хезмәт итү кирәклеге, кече Ватанга мәхәббәт тәрбияләү, үз халкыңның, туган ягыңның чын патриоты булу мөһимлеге турында сөйләде.

Нәкъ менә шундый очрашулар үз илең өчен горурлык хисе тәрбияләргә ярдәм итә. Бу көнне конкрет мисалда укучылар чын геройларның янәшәдә яшәвен, батырлык, Ватанга мәхәббәт – чын кешенең сыйфатлары икәнен күрде.

Россия халкы элек-электән сугышчан батырлыклары һәм Ватан файдасына үз-үзләрен корбан итүләре белән дан тоткан.

Төрле елларда безнең мәктәпне тәмамлаучылар арасында бүгенге көндә фронтның алгы сызыгында булучылар бихисап һәм аларның һәрберсе илебез өстендә тыныч күк йөзе өчен көрәш алып бара. Без аларның барысына да Ватаныбызны саклаганнары өчен рәхмәтле!

*Рөстәм ХАЙРЕТДИНОВ,*
*укытучы.*
*Түбән Новгород өлкәсе, Сафаҗай.*

podpiska-pochta.ru

***Бөтен гомерен авыл хуҗалыгы өлкәсенә багышлаган талантлы бригадир, совхоз директоры, «Хезмәт Кызыл Байрагы» (1960), «Почет Билгесе» (1966) орденнары иясе, КПССның XXII съезд делегаты, ТАССРның Югары Советы депутаты булган Асия Садыйк кызы Садыйковага «тынгысыз» дигән сүз бик килешә иде дип әйтәләр аның белән таныш булган, аның кул астында эшләгән кешеләр.***

**Авыл хатынының Мәскәүгә баруы**

1958 ел. Фермадагы үрдәкләрне ашатырга азык юк, район һәм республика җитәкчеләре барысы да, сөйләшеп куйгандай, «комбикорма юк» дип тәкрарлыйлар. Кулыңны селтә дә кайтып кит, 10 бригадирның тугызы шулай эшләр иде, ләкин тынгысыз Асия генә түгел. Эшкә алынгансың икән, аны яхшы итеп, башкаларга үрнәк итеп башкарып чыгарга кирәк. Вөҗданы шулай куша аның. «Миннән киткәнче, иясенә җиткәнче» дип эшләгән эш нәрсәгә кирәк ул.

Күз курка – куллар эшли. Икенче көнне Асия Садыйкова поезд белән Мәскәүгә китеп барды. СССР Авыл хуҗалыгы министрлыгының кабул итү бүлмәсендә караңгы бер авылдан килгән хатынның министр белән очрашырга теләве министрлык эшчеләренә бераз көлке хисе уятса да, ахырда алар Асиянең үҗәтлегенә, куркусызлыгына шаккаттылар. Мең чакрымга якын юл үтеп килгән авыл хатыны үзенең максатына ирешә. Министр 400 тонна комбикорманы Атабай үрдәк үстерү бригадасына җибәрү буенча наряд имзалый.

Әлбәттә, республикага кайткан әлеге азыкны башкалар белән дә бүлешергә туры килә. Ләкин эш анда түгел. Эш Асия Садыйкованың үз хезмәтенә тугры булуын, авырлыклар алдында сынмавын күрсәтә.

Авыл хуҗалыгы министрлыгыннан чыккач та Асия кире вокзалга ашкына. Поезд аны салмак кына тирбәтеп туган ягына алып кайта. Асиянең үрдәк бригадасын җитәкли башлаганнан бирле күзенә йокы керми дә башлаган иде инде. Ләкин бүген җилкәсеннән бер йөк төште бит, кош-кортларга ашатырга азык булачак. Шушы рәхәтлек хисе белән куанган 35 яшьлек хатынның күз кабаклары авыраеп, аны бик ерakka, сабый чагына алып китте...


ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА
МАКТАУ ГРАМОТАСЫ
САДЫКОВОЙ А.С.
бригадиру утиной фермы
совхоза "Комсомольский"
ЗА ВЫРАЩИВАНИЕ В 1962 ГОДУ 258,6 ТЫСЯЧИ ГОЛОВ УТЯТ И СДАЧУ ГОСУДАРСТВУ 4434 ЦЕНТ. УТИНОГО МЯСА.
25 декабря 1963 года.
Директор ВДНХ ТАССР: /Айтуганов/.

**Атабай**

Асия Садыйкова 1924 елның 23 сентябрендә Лаеш районының Атабай авылында ярлы крестьяннар – Садыйк белән Бибигайшә гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе Садыйк Атабайда туып-үскән булса, әнисе Бибигайшә чыгышы белән күршедәге Сингел авылыннан була.

Садыйк Шәрип улы 1929-1930 елларда Атабайда оешкан беренче колхоз председателе булган кеше. Әтисе вафат булганда Асиягә – 12, ә сеңлесе Саниягә 7 яшь була. Авылда 1937 елда 7 еллык мәктәп ачылгач, Асия үзеннән 2-3 яшькә кече булган балалар белән 7 нче класны укып бетерә. Ә 1940 елдан буйга җиткән кыз колхозда төрле эшләрдә эшли башлый.

Бөек Ватан сугышы башлангач, 17 яшьлек Асия «Камский» колхозының урак уру, ашлык суктыру, чистарту белән шөгыльләнә торган бер бригадасына җитәкчелек итә. Ул ирләр кебек каты куллы, һәр эшкә тәвәккәл һәм оештыру сәләтенә ия була. Үз кул астында эшләгән һәр кешедән төгәллек, эшнең сыйфатын һәм вакытында башкарылуын таләп итә.

Сугыш тәмамлангач, 1945 елдан башлап Асиянең тормышында 10 еллык Леспромхоз чоры башлана. Ул Атабай урман кисү пунктына мастер булып эшкә урнаша. Бу чорда Лаеш леспромхозында өч утын әзерләү пункты эшләгән: Мансурово, Мысы һәм Атабай. Агачларны кыш көнне кисеп яр буена җыйнап куялар, ә җәен баржаларга төяп Россиянең төрле төбәкләренә җибәрә торган булганнар. Сугыш вакытында урман кисү, утын әзерләү өчен Атабай авылында махсус тоткыннар лагере да оештырылган. Сугыш беткәч тә бу эш дәвам иткән.

**Гаилә**

Бөек Ватан сугышы беткәч, авылга бер-бер артлы ветераннар кайта башлый. 1945 елның сентябрендә I группа инвалид, орден-медальләр белән бүләкләнгән Ватан сугышы ордены кавалеры Габделхак Хөсәенов та кайтып төшә. Фронттан кайту белән Габделхак Исхак улы Лаеш леспромхозының Атабай лесоучастогы кибетенә эшкә урнаша. Халык теләндә ул кибетне «Сал кибете» дип атап йөрткәннәр.


1947 елның июль аенда сугыш ветераны Лаеш леспромхозының Мансурово авылының лесопунктына урман кисүче итеп күчерелә. Ул вакытта булачак хатыны Асия да Мансурово авылының лесопунктында технорук булып эшли торган була. Кыскасы, шул көннән башлап Асия белән Габделхак бер оешмада эшли башлыйлар.

Озак та үтми, 1948 елның яңа елыннан соң яшьләр тормышларын бергә бәйләп җибәрәләр. Гаиләдә бер-бер артлы 4 балалары туа.

**Пекин үрдәкләре һәм Хрущев белән очрашу**


1950 нче еллар ахырында Куйбышев сусаклагычы төзелеп беткәч, Кама елгасының сулары хәзерге Атабай ярларына кадәр килеп җитә. Чәчүлек мәйданнарының күпчелеге су астында калу сәбәпле, ТАССРның Югары Советы «Комсомольский» совхозының Атабай авылы фермасында үрдәк үрчетү эшен башлау буенча кирәкле күрсәтмәләрен бирә. 1957 елда Пекин токымлы үрдәкләр кайтартылып, аларны элеккеге спецлеспромхозның биналарына урнаштыралар. 1958 елда элекке бригадир урынына алмашка Асия Садыйкованы тәкъдим итәләр. Ул җиң сызганып эшкә керешә.

1959 елда инкубаторда 69 мең үрдәк бәбкәсе чыгарыла. Нәтиҗәдә, аларны үстереп дәүләткә меңләгән тонна үрдәк ите тапшырыла. 1960 елда Асия Садыйкова бригадасына «Коммунистик хезмәт бригадасы» исеме бирелә. Икенче көнне бригадирның үзен Партия обкомына Казанга чакыралар. Алкышлар астында ТАССРның Министрлар Советы рәисе Габделхак Әбдерәзәков Асия Садыйкованы Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкли.


Депутат булып сайлану турында
ТАНЫКЛЫК
№5 Атабай сайлау округының
авыл сайлау округы иseme
Округ сайлау комиссиясенең тавышка кую беркетмәсе һәм „Татарстан АССР хезмәт ияләре депутатларының район, шәһәр, авыл һәм поселок Советларына сайлаулар турындагы положение“ның 102 һәм 103 статьялары нигезендә, хезмәт ияләре депутатларының Атабай сайлана торган авыл Советына сайлаулар буенча Округ сайлау комиссиясе
Садыкова фамилиясе,
Асия исеме,
Садык кызы һәм атасының исеме иптәшнен
1959 елның 1 март сайлауларның көне, ае
№5 Атабай сайлау округының
авыл сайлау округыннан Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы Столбище районы хезмәт ияләре депутатларының Атабай сайлана торган авыл Советына депутат булып сайланганлыгын таныклый.
Округ сайлау комиссиясе председателе
П. у.
Округ сайлау комиссиясе секретаре
2 Март 1959 ел
таныклык бирелгән көн, ай

# Тынгысыз

## Асия Садыйкова тууына – 100 ел



Асия Садыйкованың үрдәк үстерүчеләр бригадасы турында газеталарга, журналларга язалар. Казаннан рәссамнар килеп үрдәк үстерүче кызларның портретларын ясыйлар. Ә бер көнне авыл халкы өчен бөтенләй дә көтелмәгән хәл була, Атабай авылына «Кинохроника» студиясе килә. Режиссерлары бик таләпчән. Ул кушканда гына көләсе, ул күрсәткән якка гына борыласы. Кино төшерүчеләр киткәч: «Бер тапкыр кинога төшкәнче 3 мең үрдәк үстерәм мин», – дип көлешәләр кызлар.

Югары күрсәткечләрен исәпкә алып бригадир Асия Садыйкованы Совхоз коммунистлары делегат итеп сайлап, өлкә партия конференциясенә җибәрәләр, ә өлкә партиясе аны КПССның XXII съезд делегатлары исемлегенә дә кертә.

1961 елның 17-31 октябрендә Мәскәүдә узган съезд хатирәләрен Асия дәфтәренә язып бара, авылга кайткач түкми-чәчми сөйләп бирәсе бар бит.

Кире туган авылына әйләнеп кайткач, кабат эш. Бүрек, бишмәт, кәлүшле киез итек. Бригадирларның кайтканын ишеткәннәр, Асияне әйләндереп алып, съезд турында сөйләргә сорыйлар.

Ә ул шул ук. Бүрек кырыеннан озын кара толымнары, каракучкыл йөзендәге куе кашлары һәм иң мөһиме тынгысыз холкы:

– Бер кат эшләрне карап чыгыйк та, кызыл почмакта җыелышып сөйләшербез. Озак-озак итеп сөйләштеләр, күбрәк Асия Садыйкова сөйләде. Съезд делегатларының Сталин җәсәден мавзолейдан чыгартып җирләү өчен тавыш бирүләре, Яңа Устав кабул ителү, 1980 елда коммунизм булачагы турында һәм дәфтәренә теркәп барган башка кызыклы күзәтүләре белән бүлеште бригадир.

Әле яңа гына Асия Садыйкова Никита Хрущев белән бер залда утырган булса, ә хәзер ул кабат бетмәс-төкәнмәс эш арасында. Фермада 11 мең ана үрдәк сайлап алырга кирәк, җәйгә ярты миллион бәбкә үстерәсе бар, алар өчен яңа брудергаузлар төзетәсе булачак.

Иртәнге биштә чыгып китә дә, караңгы төшкәнче фермада. Соңыннан ире белән кечкенә мәктәпкә 9 нчы сыйныфны укырга баралар. Әле шуның өстенә Асия Эшче депутатларның район советы депутаты да. Төрле мәсьәләләр буенча ярдәм сорап өенә дә, фермага да килүчеләр өзелми.

Ә 1963 елда Асия Садыйковага тагын бер мөһим вазыйфа өстәлә, тынгысыз бригадирны ТАССРның Югары Советы депутаты итеп сайлыйлар. 1966 елда хезмәттәге уңышлары өчен Асия Садыйк кызы «Почет Билгесе» ордены белән бүләкләнә.

1981 елда авыл хуҗалыгы өлкәсенә 40 елдан артык гомерен багышлаган, гади эшчедән башлап төрле югарылыктагы җитәкче урыннарда хезмәт иткән Асия Садыйк кызы лаеклы ялга китә. 2002 елның 7 маенда тынгысыз Асия Садыйкова 78 енче яшендә бакыйлыкка күчә.

*Булат ИБРАҺИМОВ.*
*(Фотолар Асия Садыйкованың улы Ринат Хөсәеновның шәхси архивыннан алынды).*



# «Гөлҗамал»ны дөньяга таныткан Сәйдә

*«Кызым, «Гөлҗамал» җырының дөньякүләм рейтингка кергәнен дә әйт инде». «И-и, ул турыда сөйләргә оныткамын да», – ди Сәйдә, әнисенә бераз елмаеп... Берәү булса шундый уңышы турында интернет челтәрләрендә мактаныр иде. Ә Сәйдә Мөхәммәтҗанова тыйнаклыгы белән аерылып тора. Бәлки җырчы буларак бу сыйфат аңа бик комачаулый дадыр. Ләкин гаиләдә чын татар кызларына хас сыйфатларны алып тәрбияләнгән кыз бүген үз көченә, үз сәләтенә һәм моңлы тавышына таянып әкрен генә алга атлый. Үзбәкстанда узган «Ovoz» («Голос») проектында катнашып Сәйдә МӨХӘММӘТҖАНОВА ярымфиналга чыкты. Сайлап алу турында тамашачыны халкыбызның «Гөлҗамал» җыры белән шаккаттырса, соңрак ул үзбәк телендә җырлап тагын бер сокландырды.*



**Сәйдә, без соңгы тапкыр моннан 4 ел элек әңгәмә корганбыз икән. Ул вакытта студент идегез. Мин әле сайлау алдында: һөнәр алырга телим, җыр юнәлешендә китү-китмәү турында уйлыйм дигән идегез. Бүген инде сезнең иҗат юлында зур уңышлар да бар. Тормышыгыздагы төп юлны да сайлагансыз кебек?**



– Әйе, үз юнәлешемне сайладым дип әйтә алам. Юлымны җыр буенча профессиональ дәрәҗәдә дәвам итәргә уйлыйм.

**Сез күптән түгел Үзбәкстанда узган «Ovoz» («Голос») проектында катнашып ярымфиналга чыктыгыз. Ә 2015 елда Мәскәүдә «Голос. Дети» проектында катнашкан идегез. Ул вакытта да бу конкурс юлын узу катлаулы, сынаулы булды. Ни өчен кабат әлеге юлны узарга булдыгыз?**

– Бу көтелмәгәндә генә килеп чыкты. Моның өчен әниемә рәхмәтлемен. Ул интернет челтәрләрендә Үзбәкстанда шундый проект үтүен белгәч, миңа: «Кызым, катнашып карамыйсыңмы? Үзбәкстанда беренче тапкыр уза», – диде. Катнашырга булдым! Гаризаны тутырдым, мине кастингка чакырдылар һәм тыңлауларны уздым.

**Бу ике проект арасында сезнең өчен нindидер аерма һәм үзенчәлек булды?**

– Бу проект Голландия франшизасы буенча үтә. Шуңа күрә аны уздыру тәртибендә аерма юк, бертөрле. Ләкин Россиядә үткән «Голос. Дети» проекты белән чагыштырганда, Үзбәкстандагы проектта татар җырын уздыру җиңелрәк булды. Мәскәүдә мөхәррирләрне үгетләргә кирәк иде. Ә «Ovoz»да музыкаль мөхәррирләр үзләре үк: «Сез бит инде татарча җырлыйсыздыр?» – дип сорады. Мин, әлбәттә, дидем.

**«Гөлҗамал» җырын башкаруыгызны зал тулы тамашачы йотлыгып тыңлады. Бу, бер яктан, горурлык, икенче яктан, зур җаваплылык.**

– Әйе. Анда шундый сөенечле хәл дә булды. Инде әйткәнемчә, бу проект Голландия франшизасы буенча төшерелә һәм аның хуҗалары әлеге проект кайсы илләрдә бара, шунда яңгыраган иң популяр, иң яхшы җырлардан рейтинг төзи. «Гөлҗамал» җыры әлеге халыкара рейтингка ике тапкыр керде. Башта «Проектта атнаның иң яхшы җыры», аннары «Проектта айның иң яхшы җыры» буларак.

**Бу, әлбәттә, зур казаныш. Ә проектта Татарстаннан килгән кызны башка катнашучылар, остазлар ничек кабул итте?**

– Мине бик җылы каршы алдылар. Катнашучылар арасында Татарстанны белмәгәннәр безнең мәдәниятебез, гореф-гадәтләребез белән дә кызыксына башлады. Жюри әгъзалары да бик җылы кабул итте. Севара беренче минутлардан ук борылды. «Ялла» төркеме җитәкчесе Фаррух Закиров соңрак үземә генә: «Сине үземнең төркемдә күрергә теләгән идем, ләкин мине сайламадың», – диде. Остазлар арасында Севара булуын белгәч шулкадәр сөендем, чөнки мин аның фанаткасы. Аның белән эшләп карыйсым килгән иде. Ул – чын профессионал.

**Севарадан үзегез өчен нинди тәҗрибә алдыгыз?**

– Музыкаль яктан караганда, элек җырлаганда импровизацияләр ясарга курка идем. Севара безгә мастер-класслар күрсәтте. Ул, мәсәлән, берәр аккорд бирүгә үзбәк мелизмнары белән импровизация ясый ала. «Вау» дип аңа сокландым. Минем дә бит шулай эшлисем килә дип уйладым. Хәзер шул мастер-класслардан соң импровизацияләр килеп чыга башлады, курку хисе кимеде. Севара: «Син бик тыйнак кыз, бу тыйнаклыктан бераз китәргә, кыюрак булырга кирәк, башка Сәйдәне күрсәт безгә», – диде.

**Сез, чынлап та, башка Сәйдәне күрсәтә алдыгыз. Бу ярымфиналда аеруча чагылды. Үзбәк телендә бик катлаулы җырны башкардыгыз.**

– Үзбәк телендә җырлау минем өчен кыенрак булды. «Синдә бераз акцент бар, бу сүзне болай түгел, менә шулайрак әйтергә кирәк», – диделәр. Телнең күп нечкәлекләре бар бит... Ярымфиналда Равшон Намозов репертуарыннан «Hayol» җырын башкардым. Аны миңа Севара тәкъдим итте. Ул аның яраткан җырчысы. Равшон Намозов ике ел элек вафат булган. Һәм әлеге җыр белән без җырчыны искә алдык. Җыр авыр иде. Беренче тапкыр тыңлаганнан гына ул күңелемә дә кермәде. Кабат тыңлый торгач, ошады. Аны башкарганда татар мелизмнары бөтенләй дә булмады. Әлбәттә, җырга тулысынча кереп бетәргә вакыт җитеп бетмәде. Вакыт күбрәк булса, тагын да яхшырак җырлаган булыр идем. Туры эфирда төнге унберенче яртыда гына чыгыш ясадым. Дулкынлану да булды. Аннары чыгышымны карагач, болай начар килеп чыкмаган икән дип нәтиҗә ясадым.

**Әлбәттә, бик матур чыгыш булды. Бу иҗатыгызда тагын бер баскычка югары күтәрелү дип уйлыйм. Чит илдә, чит телдә шундый югары дәрәҗәдә чыгыш ясау өчен бик зур батырлык кирәк. Мондый җирдә дуслар да, көндәшләр дә була. Үзара мөнәсәбәтләр ничек булды?**

– Безнең төркем бик дус иде. Хәзер – проект тәгәлләнгәч тә аралашабыз, социаль челтәрләрдә язышабыз. Без анда катнашучылар белән рус һәм үзбәк телләрендә дуэт эшләргә дә планлаштырабыз. Севара белән дә дуэт булачак.

**Сәйдә, сез моңа кадәр дә башка телләрдә җырладыгыз. Кытай телендә башкарган җырыгыз да халык игътибарын җәлеп итте. Ләкин чит телдә җырлау өчен аның бит нечкәлекләрен белергә, дөрес яңгырашын бирергә кирәк.**

– Әлбәттә, һәр телнең нечкәлекләрен белергә кирәк. Мисал өчен, кытай җырын өйрәнгәндә аны кытай теле укытучысы белән өйрәндем. Акцент булмасын өчен ул минем белән бу юнәлештә эшләде. Хәзер җырларымнан торган альбом әзерлибез. Якынча 10 телдә җырлаган җырлар булачак. Анда гарәп, кырым татар, кытай, хәзер менә үзбәк телендә башкарган җырлар керәчәк.

**Ә ничә телдә иркен аралаша аласыз?**

– Татар, рус, инглиз һәм төрек телләрендә.

**Сәйдә, тамашачы сезне балачактан ук белә – безнең күз алдында үстегез. Балачактан ук сәхнәдә булган кайбер җырчылар үсеп буйга җиткәч тамашачы арасында популярлыгын саклый алмый: аларны тамашачы инде кабул итми. Ә сез бу яктан бәхетле: тамашачы буйга җиткән Сәйдәне дә кабул итте. Әнә шул күчеш чорын ничек уздыгыз? Ул сизелдеме?**

– Әйе, тамашачы минем белән бергә үсте, мине үстерде. Ләкин барыбер үземә карата кайтавазлар ишетәм: мине һаман да бала дип кабул итәләр. Шундый карашлар сизәм. Берзаман мондый нәрсәләрне тою уңайсыз була башлады. Һәм мин тамашачыма башка Сәйдәне күрсәтергә теләдем. Быел ике шәхси концертым узды. Алар ике өлештән торды. Аның беренче өлешендә менә ул барыгызга да таныш булган калфаклы, ике толымлы Сәйдә. Татар халык җырлары, автор җырлары яңгырады. Икенче өлештә төрле телләрдә дөньякүләм җырларны ишеттердем. Анда мин чалбардан да, пиджактан да чыктым. Заманча биюләр дә өстәлде. Башка жанрда да җырладым. Шулай итеп икенче Сәйдәне күрсәтергә теләдем. Әйе, 9 ел элек булган Сәйдә үземә дә бик кадерле, ләкин мин үсәм. Фикерләрем, дөньяга карашым, тышкы кыяфәтем дә үзгәрә.

**Әйе, сез бүген үсештә. Җыр юнәлешендә генә түгел, үзегезне театр, кино юнәлешендә дә сынап карыйсыз. «Казан» ансамбле белән берлектә сәхнәгә куелган «Зәңгәр шәл» музыкаль спектаклендә Мәйсәрә ролен дә башкарасыз.**

– Бу миңа якын булган образ инде. Минемчә, әлеге образны бирә алдым. Күпләр булышты. Режиссер Чулпан Закировага, аның әнисе Рузия апа Мотыйгуллинага бик рәхмәтлемен. Мондый тәҗрибә булуга бик шатмын. Театр дөньясында ничек эш кайнавын күрдем. Быел «Йосыф һәм Зөләйха» спектаклендә Зөләйха ролен уйнаячакмын. Премьерага әзерләнәбез.

**Сезнең график шундый тыгыз. Иҗаттан тыш шәхси тормышка, нindидер хоббига вакыт каламы?**

– Әлбәттә, кала. Мин сәяхәт итәргә яратам. Үзбәкстанга чыгуым да шул хобби белән бәйле. Форсаттан файдаланып, Сәмәрканд, Бохара шәһәрләрендә булдым, төрле архитектура үрнәкләрен күрдем. Моңа бик шатланам. Тагын шулай башка илләрне дә күрергә насыйп булсын. Тиздән Казакъстанга барырга җыенам. Анда фестиваль узачак – шунда катнашырга телим. Казакъ телендә инде җыр сайланды. Аранжировкаларын эшлисе бар.

**Алда тагын нинди планнар бар. Шәхси концертыгыз көтеләме?**

– Әйе, инде әзерлек эшләре бара. Әлегә төгәл вакыты билгеле түгел. Ноябрь ахырында яисә декабрь башында булыр. «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгендә кызыклы гына форматта узар дип өметләнәм. Үзбәкстаннан да дусларымны чакырасы килә. Килеп чыкса, Севараны да чакырасым килә: хәзер сөйләшүләр бара.

**Сәйдә, алда бик кызыклы проектларыгыз, планнарыгыз бар. Мин сезгә зур уңышлар телим.**

*Энҗе ШӘЙХЕТДИНОВА.*

podpiska.pochta.ru